**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**

**Ятмас-Дусай авыл җирлеге башлыгы**

**карары**

**2023 елның 14 ноябре** **№7**

**«Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге Шепшеңәр авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2023 елның 28 ноябренә 09 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге Шепшеңәр авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Шепшеңәр авылы, Мәктәп урамы, 10в йорт адресы буенча урнашкан Шепшеңәр авылы мәчет бинасында үткәрергә.

2. 2023 елның 28 ноябренә 14 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге Шепшеңәр авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Шепшеңәр авылы, Мәктәп урамы, 10в йорт адресы буенча урнашкан Шепшеңәр авылы мәчет бинасында үткәрергә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: « укучылар һәм көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан (курсантлар); I төркем инвалидлардан; 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге Шепшеңәр авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2024 елда үзара салымны 4000 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

-Шепшеңәр авылында урам яктырту лампаларын, яктырткычларны, махсус җиһазларны һәм башка төр урам яктыртуларын сатып алу, урнаштыру;

- янгын гидрантларын һәм комплектлаучыларны сатып алу һәм урнаштыру, шул исәптән проект-смета документациясе һәм технадзорны гамәлгә ашыру;

-Шепшеңәр авылы территориясен төзү, ремонтлау һәм төзекләндерү, проект-смета документациясен эшләү;

-Шепшеңәр авылында вак таш белән юлларны түшәү, төзү,карап тоту, төзекләндерү, шул исәптән проект-смета документациясе һәм технадзорны гамәлгә ашыру;

- янгынга каршы җиһазлар һәм комплектлаучы җиһазлар (килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, смета, технадзор һәм документлар өчен түләү)сатып алу, урнаштыру һәм тоту;

- сусуткәргеч челтәрләрен һәм су күтәрү манараларын ремонтлау, тоту, төзекләндерү ( Шепшеңәр авылының артезиан манарасы өчен насос сатып алу, материаллар сатып алу, проект-смета документациясен эшләү, килешү буенча түләү);

-Шепшеңәр авылында күперне төзү һәм ремонтлау, шул исәптән проект-смета документациясе һәм технадзорны гамәлгә ашыру;

- Шепшеңәр авылында зират территориясен саклау һәм төзекләндерү, (хуҗалык инвентары, җиһазлар һәм ремонт өчен материаллар сатып алу), проект-смета документациясен үтәп;

-Шепшеңәр авылында юлларны кышкы-җәйге тоту (проект-смета документациясен эшләү, килешү буенча түләү);

- Шепшеңәр авылында чишмәне ремонтлау,төзекләндерү, карап тоту, проект-смета документациясе, технадзорны гамәлгә ашыру, материалны сатып алу, ташу һәм чишмәне төзекләндерү һәм тоту буенча башка эш төрләре.

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

5. Гражданнар җыенын оештыручы итеп, Ятмас-Дусай авыл Башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Ятмас-Дусай авыл җирлеге башлыгы: Ф. Х. Гарифуллина